**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Аблязкино ав. **КАРАР**

«08» февраль 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы җирлегенең Аблязкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Аблязкино авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү, элек расланганнарга өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 19 февраленә Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Аблязкино авылы адресы буенча Аблязкино кибете янында 14 сәгать 00 минутка билгеләргә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Аблязкино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 25 ноябрендәге 7 номерлы карарына;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Аблязкино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 25 ноябрендәге 8 номерлы карарына.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Аблязкино авылында яшәүче гражданнар өчен тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Аблязкино авыл җирлегендә 2023 елның 25 ноябрендәге 7 номерлы гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы

Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авыл җирлегендә 2023 елның 25 ноябрендәге 8 номерлы гражданнар җыены карары турында элек расланган карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино авылы территориясендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым тәртибендә 1000 сум күләмендә алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эш исемлеген түбәндәге эш төрләре белән тулыландырырга:

- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм Абляскино торак пункты чикләрендәге юлларны сезонлы тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Абляскино авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Б. Храбров